**Казан шәһәре Думасының**
**2025 елның 12 августындагы 8-40 номерлы карары**

**Казан шәһәре Думасының**
**2006 елның 17 февралендәге 2-6 номерлы «Казан шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләрне оештыру тәртибе турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, муниципаль хокукый актларны камилләштерү максатыннан Казан шәһәре Думасы **карар бирде:**

1. Казан шәһәре Думасының 2006 елның 17 февралендәге 2-6 номерлы «Казан шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру тәртибе турында»гы карары кушымтасына (Казан шәһәре Думасының 2006 елның 23 августындагы 47-11 номерлы, 2012 елның 19 апрелендәге 11-13 номерлы, 2014 елның 28 августындагы 3-35 номерлы, 2015 елның 28 октябрендәге 7-2 номерлы, 2016 елның 16 августындагы 17-9 номерлы, 2020 елның 12 августындагы 4-41 номерлы, 2021 елның 5 октябрендәге 5-9 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 статьяда:

1.1.1. 1 өлештә «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законы» сүзләрен «2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы “Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы федераль законы» сүзләренә алмаштырырга;

1.1.2. 2 өлештә «уналты яшькә» сүзләрен «унсигез яшькә» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 5 статьяның 2 өлешендәге 3) пунктында «территориаль иҗтимагый үзидарәнең Казан шәһәренең тиешле территориясендә,» сүзләреннән соң «территориаль иҗтимагый үзидарә органнары структурасын билгеләү, территориаль иҗтимагый үзидарә органнарын сайлау,» сүзләрен өстәргә;

1.3. 6 статьяда:

1.3.1. 1 өлешнең икенче абзацын төшереп калдырырга;

1.3.2. 2 өлештә:

1.3.2.1. икенче абзацта «әлеге статьяның» сүзләрен «5 статьясындагы» сүзләренә алмаштырырга;

1.3.2.2. өченче абзацта «инициатив төркем тарафыннан тәкъдим ителгән документларга» сүзләрен «инициатив төркем тарафыннан тәкъдим ителгән документларда» сүзләренә алмаштырырга;

1.3.3. 8 өлешне төшереп калдырырга;

1.4. 6.1 статьяда:

1.4.1. 1 өлештә:

1.4.1.1. бишенче абзацта «уналты яшькә» сүзләрен «унсигез яшькә» сүзләренә алмаштырырга;

1.4.1.2. тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Район администрациясе җыелышларның беркетмәләре нигезендә территориаль иҗтимагый үзидарәләрнең чикләрен билгеләү турында Шәһәр Думасы карарлары проектларын әзерли, аларда түбәндәгеләр булырга тиеш:»;

1.4.1.3. унберенче абзацта «(фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган көнен, яшәү урыны адресын күрсәтеп)» сүзләрен өстәргә;

1.4.1.4. түбәндәге эчтәлекле унөченче абзац өстәргә:

«Территориаль иҗтимагый үзидарә чикләрен билгеләү турында Шәһәр Думасы карарлары проектлары Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан Шәһәр Думасына әлеге пунктның 10-12 абзацларында күрсәтелгән документларны кушып, бер үк вакытта шәһәр Думасы регламенты нигезендә теркәп бирелә торган бер хат белән кертелә»;

1.4.2. 4 өлешнең унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Район администрациясе территориаль иҗтимагый үзидарәләрнең чикләрен билгеләү турында Шәһәр Думасы карарлары проектларын әзерли. Яңа төзелә торган территориаль иҗтимагый үзидарәнең чикләрен билгеләү һәм гамәлдәге территориаль иҗтимагый үзидарәнең чикләрен үзгәртү турында Шәһәр Думасы карарлары проектлары Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан Шәһәр Думасына әлеге пунктның җиденче абзацында күрсәтелгән документларны кушып, бер үк вакытта Шәһәр Думасы регламенты нигезендә

теркәп бирелә торган бер хат белән кертелә»;

1.4.3. 5 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җиденче абзац өстәргә:

«Район администрациясе территориаль иҗтимагый үзидарәләрнең чикләрен билгеләү турында Шәһәр Думасы карары проектын әзерли. Берләштерелгән территориаль иҗтимагый үзидарә чикләрен билгеләү турында Шәһәр Думасы карары проекты, әлеге пунктның алтынчы абзацында күрсәтелгән документларны кушып, Шәһәр Думасына Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан Шәһәр Думасы регламенты нигезендә кертелә»;

1.4.4.  6 өлешнең җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Район администрациясе территориаль иҗтимагый үзидарәләрнең чикләрен билгеләү турында Шәһәр Думасы карарлары проектларын әзерли. Яңа төзелә торган территориаль иҗтимагый үзидарәләрнең чикләрен билгеләү турында Шәһәр Думасы карарлары проектлары Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан Шәһәр Думасына, әлеге пунктның алтынчы абзацында күрсәтелгән документларны кушып, бер үк вакытта Шәһәр Думасы регламенты нигезендә теркәп бирелә торган бер хат белән кертелә»;

1.4.5. 7 өлештә:

1.4.5.1. дүртенче абзацта «җыелышның (конференциянең) тиешле беркетмәсе кушымтасы белән» сүзләрен өстәргә;

1.4.5.2. түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Район администрациясе территориаль иҗтимагый үзидарәнең элек билгеләнгән чикләрен үзгәртү турында Шәһәр Думасы карары проектын әзерли. Территориаль иҗтимагый үзидарәнең элек билгеләнгән чикләрен үзгәртү турында Шәһәр Думасы карары проекты, Шәһәр Думасы Регламенты нигезендә әлеге пунктның дүртенче абзацында күрсәтелгән документларны кушып, Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан Шәһәр Думасына кертелә»;

1.4.6. 8 өлештә:

1.4.6.1. бишенче абзацта «җыелышта (конференциядә) катнашучыларның» сүзләреннән соң «(фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган көнен, яшәү урынының адресын күрсәтеп)» сүзләрен өстәргә;

1.4.6.2. алтынчы абзацта «уналты яшькә» сүзләрен «унсигез яшькә» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 7 статьяны түбәндәге редакциядә бирергә:

«7 статья. Оештыру җыелышы (конференция)

1. Оештыру җыелышын (конференцияне) оештыруны һәм уздыруны гражданнарның инициатив төркеме тәэмин итә.

2. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру күздә тотылган территориядә 200 дән артык кеше яшәгән очракта, оештыру конференциясе уздырылырга мөмкин.

3. Оештыру конференциясенә делегатлар саны 10 кешедән дә ким була алмый һәм вәкиллекнең нормасын 20 гражданнан кимендә 1 вәкил тәэмин итәргә тиеш.

4. Оештыру конференциясе үткәрелгән очракта, инициатив төркем конференция делегатларын гражданнар җыелышларында яисә алар вәкилләре булган гражданнарның имзаларын җыю юлы белән сайлап алуны оештыра.

5. Оештыру җыелышын (конференциясен) җыю, аны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында инициатив төркем, аны үткәрүгә кимендә 7 көн кала тиешле территориядә яшәүчеләргә мәгълүматны әлеге территориядә яшәүче барлык кызыксынучыларга җиткерүне тәэмин итә торган теләсә нинди формада (белдерүләр урнаштыру, фатирларны йөреп чыгу һ.б.), шулай ук район администрациясенә язма рәвештә хәбәр итә.

6. Оештыру җыелышы (конференция) башланыр алдыннан җыелышка (конференциягә) килгән тиешле территориядә яшәүчеләрне (конференция делегатларын) теркәү уздырыла.

7. Оештыру җыелышы, әгәр анда тиешле территориядә унсигез яшькә җиткән халыкның кимендә 1/3 өлеше катнашса, тулы хокуклы дип санала.

8. Әгәр сайланган делегатларның ким дигәндә 2/3 өлеше, унсигез яшенә җиткән тиешле территориядә яшәүчеләрнең ким дигәндә 1/3 өлешен тәкъдим итсә, оештыру конференциясе тулы хокуклы.

9. Җыелышта (конференциядә) рәислек итүче һәм секретарь сайлана.

10. Җыелышны (конференцияне) үткәрү процедурасы беркетмәдә чагыла, ул җыелыш (конференция) секретаре тарафыннан ирекле язма рәвештә алып барыла һәм җыелыш (конференция) рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалана.

11. Район хакимияте оештыру җыелышында (конференциядә) киңәш бирү тавышы хокукы белән катнашу өчен үз вәкилен җибәрә.

12. Оештыру җыелышында (конференциядә) түбәндәге карарлар кабул ителә:

- тиешле территория чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру турында;

- территориаль иҗтимагый үзидарә органнары структурасын билгеләү турында;

- территориаль иҗтимагый үзидарә органнарын сайлау турында;

- территориаль иҗтимагый үзидарә Уставын кабул итү турында;

- территориаль иҗтимагый үзидарә Уставын теркәү белән бәйле мәсьәләләрне караганда территориаль иҗтимагый үзидарәне тәкъдим итәргә вәкаләтле вәкилне (вәкилләрне) сайлау турында.

Күрсәтелгән карарлар ачык тавыш бирү юлы белән гади күпчелек тавыш белән кабул ителә.

13. Территориаль иҗтимагый үзидарә чикләрен билгеләү турында Шәһәр Думасы карары үз көченә кергән көннән алып алты ай эчендә территориаль иҗтимагый үзидарә Уставын теркәү өчен документлар тапшырылмаган очракта, территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру буенча гамәлләр туктатылган дип санала. Шул ук вакытта район администрациясе тиешле территориаль иҗтимагый үзидарә чикләрен билгеләү турында Шәһәр Думасы карарының үз көчен югалтуын тану турында карар проектын әзерли. Күрсәтелгән карар проекты Шәһәр Думасы Регламенты нигезендә Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан Шәһәр Думасына кертелә»;

1.6. 9 статьяда:

1.6.1. 1 өлешнең 1), 2) пунктларын түбәндәге редакциядә бирергә:

«1) гражданнар җыелышының (конференциясенең) вәкаләтле вәкиле (вәкилләре) тарафыннан имзаланган территориаль иҗтимагый үзидарә Уставын теркәү турында гариза (алга таба – Уставны теркәү турында гариза);

2) территориаль иҗтимагый үзидарәне төзү турында карар кабул ителгән гражданнарның оештыру җыелышы (конференциясе) беркетмәсе, шулай ук җыелышның (конференциянең) хокукый булуын раслый торган җыелышта (конференциядә) катнашучыларны теркәү турындагы белешмәләр»;

1.6.2. 4 өлештә «30 көн эчендә» сүзләрен «14 эш көне дәвамында» сүзләренә алмаштырырга;

1.6.3. 6 өлешнең икенче абзацын төшереп калдырырга;

1.6.4. 11 өлешне түбәндәге редакциядә бирергә:

«11. Территориаль иҗтимагый үзидарә Уставы теркәлгән очракта, Уставның, аны теркәү турында тамгасы булган, ике нөсхәсе, шулай ук Уставны теркәү турында муниципаль берәмлек башлыгы күрсәтмәсенең билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәсе гражданнар җыелышының (конференциясенең) вәкаләтле вәкиленә тапшырыла, Уставның өченче нөсхәсе шәһәр Думасы аппаратында саклана»;

1.6.5. 13 өлешнең 4) пунктына «күрсәтелгән вәкаләтләр бирелгән очракта» сүзләрен өстәргә;

1.6.6. 14 өлештә «15 өлешендә» сүзләрен «13 өлешендә» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 10 статьяда:

1.7.1. 3 өлешкә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеге югарыда күрсәтелгән нигезләр буенча туктатылган очракта, район хакимияте тиешле территориаль иҗтимагый үзидарә чикләрен билгеләү турында Шәһәр Думасы карарының үз көчен югалтуын тану турында карар проектын әзерли. Күрсәтелгән карар проекты Шәһәр Думасы Регламенты нигезендә Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан Шәһәр Думасына кертелә»;

1.7.2. 6 өлешне төшереп калдырырга;

1.8. 11 статьяның 1 өлешендә «территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.9. 12 статьяның 2 өлешенә «Казан шәһәре» сүзләрен өстәргә;

1.10. 13 статьяда:

1.10.1. 2, 3 өлешләрдә «уналты яшькә» сүзләрен «унсигез яшькә» сүзләренә алмаштырырга;

1.10.2. 4 өлешне түбәндәге редакциядә бирергә:

«4. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыручы гражданнар җыелышының (конференциясенең) аерым вәкаләтләренә (гражданнарның гамәлгә кую җыелышында (конференциясендә) билгеләнгән вәкаләтләрдән тыш) түбәндәгеләр керә:

1) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары структурасын үзгәртү;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарын яңадан сайлау;

4) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгеләү;

5) территориаль иҗтимагый үзидарә керемнәре һәм чыгымнары сметасын һәм аның үтәлеше турындагы хисапны раслау;

6) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы хисапларны карау һәм раслау;

7) инициативалы проект турында фикер алышу һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.

8) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеген туктату турында карар кабул итү»;

1.11. 16 статьяда:

1.11.1. 2 өлештә «казначейның» сүзен «казначей» сүзенә алмаштырырга;

1.11.2. 3 өлешне түбәндәге редакциядә бирергә:

«3. Территориаль иҗтимагый үзидарә комитеты (советы) территориаль иҗтимагый үзидарә Уставы теркәлгән вакыттан алып гражданнар җыелышлары (конференцияләре) арасындагы чорда үз вәкаләтләре чикләрендә территориаль иҗтимагый үзидарә исеменнән чыгыш ясый»;

1.11.3. 4 өлештә:

1.11.3.1. икенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«комитет (совет) рәисен аның әгъзалары арасыннан сайлау»;

1.11.3.2. дүртенче абзацта «комитет (совет)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.12. 17 статьяның 3 өлешендә «Казначей» сүзеннән соң «комитетның (советның)» сүзләрен өстәргә;

1.13. 21 статьяның 2 өлешендә «җирле үзидарә затлары тарафыннан» сүзләреннән соң «Казан шәһәренең» сүзләрен өстәргә;

1.14. 22 статьяда «милиция» сүзен «полиция» сүзенә алмаштырырга;

1.15. 23 статьяның 1 өлешенә «Казан шәһәренең» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**